ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 ноября 2016г. № 5773

«2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында

РФ Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданнар оборонасы» 03.09, «Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү» 03.10, «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01, «Гомуми белем бирү» 07.02 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына, 2017 елда – 16161,39 мең сум, 2018 елда – 16239,21 мең сум, 2019 елда – 16309,17 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы В.А. Гаврилов

Башкарма комитетның
2016 елның 2 ноябрендәге
5773 номерлы карарына
кушымта

«2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы»
муниципаль программасы

## 1 бүлек. Программаның паспорты

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td colspan="5">«2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасы (алга таба – Программа)</td></tr>
<tr><td>Программаны эшләү өчен нигез</td><td colspan="5">«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы Федераль закон), «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон)</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td colspan="5">Халык иминлеген тәэмин итү бүлеге (алга таба – ХИТИБ)</td></tr>
<tr><td>Программаны үтәүчеләр</td><td colspan="5">ХИТИБ, Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td colspan="5">янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнарның сакланышын күтәрү, аларның нәтиҗәләрен кисәтү һәм йомшарту өчен кирәкле шартлар тудыру һәм тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">- Яр Чаллы шәһәре халкын һәм территориясен саклау буенча янгынга каршы чараларны тәэмин итү;<br>- шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">1 этап – 2017 ел; 2 этап – 2018 ел, 3 этап – 2019 ел.</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>2018</td><td>2019</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>16161,39</td><td>16239,21</td><td>16309,17</td><td>48709,77</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td></td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>16161,39</td><td>16239,21</td><td>16309,17</td><td>48709,77</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка</td><td colspan="5">1. Янгыннар санын һәм янгыннарда травма алган кешеләр санын киметү.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| ашыруның кәтәлгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 2. Шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү<br>Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә янгынга кагылышлы хәлләрнең төп күрсәткечләрен сан ягыннан 2019 ел күрсәткечләрен 2015 елга карата киметүгә ирешү планлаштырыла:<br>- янгыннар санын елына 2 очракка;<br>- һәлак булучылар санын елына 1 кешегә;<br>- травма алган кешеләр санын елына 1 кешегә;<br>- елына 300,0 мең сумлык матди зыян. |
| Программа чараларын башкаручы аларны сыйфатлы һәм үз вакытында үтәү, бүлеп бирелә торган финанс средстволарыннан рациональ файдалану өчен җаваплы | Программа чараларын башкаручы аларны сыйфатлы һәм үз вакытында үтәү, бүлеп бирелә торган финанс средстволарыннан рациональ файдалану өчен җаваплы |

## 2 бүлек. Программаны кабул итү кирәклеген нигезләү

Яр Чаллы шәһәре инфраструктурасының заманча үсеше икътисадый потенциалны ныгытуга, социаль иминлекне яхшыртуга һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшәүче халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән. Икътисадый куркынычсызлыкны тәэмин итүнең мөһим һәм актуаль критерийларының берсе булып янгын куркынычсызлыгы чаралары системасын оештыру тора. Тәкъдим ителгән максатчан программаны эшләүнең максатчанлыгы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгыннан ихтыярый саклау» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яр Чаллы шәһәре чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү буенча Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкару зарурлыгына бәйле.

Яр Чаллы шәһәре территориясендә барлыкка килә торган янгыннар ел саен шәһәр икътисады һәм халкы өчен зур матди һәм мораль югалтуларга

китерә, нәтиҗәләрнең авырлыгы, кешеләрнең үлем һәм травма алу дәрәҗәсе югары булып кала бирә.

ТР буенча РФ ГХМ ДУ КЭИнең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең 2014 һәм 2015 елда Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннар һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүматлар:

| № т/б | Ел | Янгыннар саны | Зыян күргән халык саны, кеше | | Матди зыян суммасы, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | һәлак булган | травма алган | |
| 1. | 2013 (факт) | 233 | 12 | 36 | 2314832,00 |
| 2. | 2014 (факт) | 231 | 7 | 44 | 424251,00 |
| 3. | 2015 (факт) | 225 | 7 | 27 | 48170458,00 |

Күпчелек очракта янгын аерым гражданнарның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә җавапсыз мөнәсәбәте, әлеге һәлакәтнең куркыныч булуын һәм аның нәтиҗәләрен алдан күрә белмәве нәтиҗәсендә килеп чыга. Бүген һәр икенче янгын – ут белән саксыз эш итү аркасында, һәр дүртенче янгын электр җиһазларын һәм көнкүреш приборларын урнаштыру һәм файдалану кагыйдәләрен үтәмәү аркасында килеп чыга. Гомумән алганда, янгын куркынычсызлыгы нигезләрен белмәгән гражданнар гаебе белән 70% тан артык янгын килеп чыга.

Янгын чыгу сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Иң гомуми сәбәпләр булып түбәндәгеләр тора:

1. Билгеләнмәгән урыннарда тәмәке тарту һәм тәмәке төпчекләрен, шырпыны ташлау;

2. Яна торган матдәләрне саклау кагыйдәләрен бозу, бигрәк тә җылыту приборлары янында;

3. Электр җиһазыннан файдалану кагыйдәләрен бозу, аны төзек булмаган хәлдә файдалану;

4. Төзек булмаган яктырту приборларын, электр үткәргечләрне һәм очкынлана, кыска ялганыш барлыкка китерә торган җайланмаларны куллану һ. б.;

5. Яна торган матдәләрне һәм материалларны саклау урыннарында эретеп ябыштыру эшләрен үткәрү кагыйдәләрен бозу;

6. Парлар, газлар, сыеклыклар ташлауны китереп чыгаручы җиһазларның технологик эш режимнарын бозу;

7. Яшен үткәргечләр булмау, статистик электрдан саклануның техник чаралары дөрес урнашмау;

8. Материалларны һәм матдәләрне янгын куркынычы булган үзлекләрен исәпкә алмыйча куллану.

Әлеге мәгълүматлар, күбесенчә янгын куркынычсызлыгы проблемасын хәл итү, янгынга каршы белемнәр дәрәҗәсенең артуына (янгыннарны

профилактикалауга) бәйле булуны раслый.

Янгыннарны һәм кешеләр үлемен профилактикалауның бер формасы булып янгынга каршы пропаганда һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү тора.

Программаның чаралары янгыннарны профилактикалауга һәм гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычын киметүгә, Яр Чаллы шәһәрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Программа ысулы белән янгыннарны һәм кешеләр үлемен профилактикалау, кисәтү буенча бурычларны хәл итү Яр Чаллы шәһәре халкының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын тормышка ашыруның иң нәтиҗәле инструменты булып тора.

## 3 бүлек. Максаты һәм бурычлары, индикаторлары

Программаның максаты булып Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннарны кисәтү буенча нәтиҗәле система булдыру тора.

Программаның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәре халкын һәм территориясен саклау буенча янгынга каршы чараларны тәэмин итү;

2) шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Программаны тормышка ашыруның максатчан күрсәткече булып 2015 ел дәрәҗәсенә карата Яр Чаллы шәһәрендә янгын куркынычсызлыгы торышы тора.

Программаның мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

- янгыннар санын, янгыннарда травма алган кешеләр санын киметү;
- шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә социаль һәм икътисадый яктан яраклы янгын куркынычсызлыгы дәрәҗәсенә ирешү, объектларның янгынга каршы сакланышын ныгыту күздә тотыла.

## Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Башкаручы лар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Максат: янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнарның сакланышын арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү һәм җиңеләйтү өчен кирәкле шартлар тудыру һәм тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Яр Чаллы шәһәре халкын һәм территориясен саклау буенча янгынга каршы чараларны тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ материаль-техник тәэмин итү | «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ | 2017-2019 еллар | Янгыннар саны, берәмлек | 1,0 | 3,0 | 3,0 | 3,0 | 7381,39 | 7459,21 | 7529,17 |
| Бурыч: Шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» ПАК комплексны адреслы мониторинг системасына техник хезмәт күрсәтү | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | Янгыннар саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 3782,0 | 3782,0 | 3782,0 |
| Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» ПАК комплексны адреслы мониторинг системасына техник хезмәт күрсәтү | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | Янгыннар саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 4998,0 | 4998,0 | 4998,0 |
| «Яшь коткаручы» региональ кыр лагеренда катнашуга әзерлек | Мәгариф һәм яшьләр | 2017-2019 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | белән эшләү идарәсе | | | | | | | | | |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре арасында «Ут һәм кешеләр» республика конкурсында катнашу | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| Укучылар арасында янгынга каршы тематикага иң яхшы инша, иң яхшы рәсем һәм гамәли иҗат өлкәсендә иң яхшы эш конкурсы | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| барлыгы: | | | | | | | | 16161,39 | 16239,21 | 16309,7 |

## 3. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

| Индикаторның исеме | Исәпләү | Мәгълүмат чыганагы |
|---|---|---|
| Янгыннар санының кимүе, % | C= A/B*100 -100,<br>А – агымдагы елда янгыннар саны,<br>В – база елында янгыннар саны | ТР буенча РФ ГХМ ДУ КЭИнең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге |

## 4 бүлек. Программаның механизмы һәм аны тормышка ашыру сроклары

Программаны тормышка ашыру механизмы, Программаны тормышка ашыру чараларын эшләү юлы белән шәһәр бюджеты кытлыгы шартларында гамәлгә ашырылачак проблемаларны хәл итү өчен, финанс һәм оештыру-хокукый базаны үз эченә ала. 2017-2019 елларга программаны финанслау күләме 48709,77 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча 2017 ел - 16161,39 мең сум, 2018 ел - 16239,21 мең сум, 2019 ел - 16309,17 мең сум.

Программа чараларын финанслауның төп чыганагы булып шәһәр бюджеты тора.

## 5 бүлек. Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы

Программаны тормышка ашыруга агымдагы идарә, аны тормышка ашыру, ахыргы нәтиҗәгә ирешү һәм Программаны үтәүгә бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан нәтиҗәле файдалану өчен җаваплы ХИТИБ тарафыннан гамәлгә ашырыла.

ХИТИБның Программаны тормышка ашыруның бөтен чорында һәм планлаштырыла торган чаралар буенча план күрсәткечләренә ирешүне, финанслау динамикасын һәм үтәлешен бәяләп Программа үтәлеше турындагы еллык докладны, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгына һәм Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрелә.

ХИТИБ ел саен программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, аны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, Программаны тормышка ашыру механизмын, башкаручылар составын аныклый, кирәк булганда, Программаның гамәлдә булган соңгы елында аны тормышка ашыру срогын озайту турында тәкъдимнәр (нигезләп) кертә.

6 бүлек. Программа чараларын башкаручыларның шартлы билгеләре

| | |
|---|---|
| Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | Башкарма комитетның Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе |
| ХИТИБ | Халык иминлеген тәэмин итү бүлеге |
| «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ | «Янгын сүндерү-коткару отряды» муниципаль бюджет учреждениесе |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова